Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский ис. авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАРЫ

дата«02» апрель 2021 ел № 7

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский ис. авыл җирлеге Башкарма комитетының "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 2020 елның 4 февралендәге 2 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 15.01.2021 № 11/13-09/111, 22.01.2021 елдагы 11/13-09/236 номерлы хатларын карап, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский ис. авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский ис. авыл җирлеге Башкарма комитетының “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтанын 3.4. бүлегенең 3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 абзац өстәргә:

"мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы (булуы) турында мәгълүматлар, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш».

2.Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Башлык С. Г. Юдин